**Казан − спорт башкаласы**

**<u>Рәсми Татарстан</u>** http://tatarstan.ru/tat/about/sport.htm

**Спорт**



Татарстан Республикасы - Россия Федерациясе төбәкләре арасында спорт лидерларының берсе.

Спорт белән шөгыльләнү өчен барлык урыннарда шартлар тудыру, спорт корылмалары төзелеше Татарстанда киң катлау халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруның нигезенә әверелде.

Спорт инфраструктурасында 9175 спорт корылмалары санала.

Республиканың барлык районнарында спортның төрле төрләре белән шөгыльләнү

өчен заманча спорт комплекслары бар. Боз сарайларының гомуми саны гына да 35кә җитә һәм бу илдәге иң яхшы күрсәткеч.

Мөмкин кадәр күп кешене физкультура һәм спорт белән шөгыльләнергә эндәү, һәркем кулланырлык һәм алга киткән спорт инфраструктурасын булдыру, җәмгыятьтә сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтен формалаштыру республикада физкультура һәм спортны үстерүнең төп юнәлеше булып тора.

Массакүләм спорт республикада зур үсеш ала, ул мәгариф һәм яшь буынны тәрбияләү системасына актив кертелә.

Халык арасында мәдәни-массакүләм эшләрне үстерү өчен сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруның яңа формалары кулланыла. Республика укучылары арасында, югары уку йортлары һәм урта махсус уку йортлары, дәүләт хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр арасында, пенсионерлар һәм инвалидлар арасында Спартакиадалар уздырыла.

Ел саен түбәндәге спорт чаралары оештырыла: Татарстан Республикасы укучылары Спартакиадасы, ТР гомуми белем бирү учреждениеләре

командалары арасында мәктәп баскетбол лигасы чемпионаты, мәктәп укучылары арасында үткәрелүче бөтенроссия “Президент ярышлары” спорт ярышларының һәм бөтенроссия “Президент спорт уеннары” спорт уеннарының, футбол буенча “Күн туп” бөтенроссия турнирының республика этаплары.

Ел саен республикада “Россия чаңгы юлы” һәм “Татарстан чаңгы юлы”, “Милләт кроссы” һәм “Татарстан кроссы” дигән массакүләм спорт ярышлары үткәрелә.

Яшьләр инфраструктурасы да камилләштерелә. Республикада 250 дән артык яшьләр учреждениеләре һәм 162 балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләре эшли.

Үсеп килүче буын өчен спортның техник һәм экстремаль төрләре үсешенә зур игътибар бирелә – республика спорт комплекслары каршында картинг, паркур, скейтинг, роллинг өчен махсус мәйданчыклар ясала, анда яшьләргә спорт белән түләүсез шөгыльләнергә мөмкинлекләр бар.

Илнең зур фәнни-мәгариф һәм студентлар үзәге булган Татарстан башкаласы - Казан шәһәренең спорт һәм шәһәр инфраструктурасын үстерүгә республикада тормышка ашырыла торган зур халыкара спорт проектлары да этәргеч бирде.

Соңгы иң зурлары: яшүсмерләр арасында җиңел атлетика буенча Россия беренчелеге, Идел буе федераль округы югары уку йортлары арасында футбол буенча Бөтенроссия ярышлары, бадминтон буенча Татарстан Республикасы беренчелеге финалы, 2013 елда суга сикерү буенча Гран-при FINA сериясенең XIX ярышы, ирләр һәм хатын-кызлар арасында авыр атлетика буенча Россия чемпионаты, фехтование буенча “Весенняя капель” Бөтенроссия турниры, волейбол буенча яшьләр командалары арасында Россия кубогы финалы, синхрон йөзү буенча Россия чемпионаты, йөзү буенча Россия кубогы финалы, яшүсмерләр командалары арасында Россия балалар-яшүсмерләр баскетбол лигасының XII беренчелеге, суга сикерү буенча яшүсмерләр арасында Россия беренчелеге, студентлар арасында

“Көрәш” һәм билбаулы көрәш (ирекле стиль), спорт гимнастикасы буенча Татарстан Республикасының ачык шәхси кубогы.
Спорт тормышында иң мөһим вакыйгаларның берсе – 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиада.
2013 елгы **Универсиаданы** уздыру өчен 64 спорт объекты файдаланылган, шуларның 30ы – яңа төзелеш объектлары.

Ярышларга махсус төзелгән иң зур объектлар:

- 45 мең урынлык **футбол стадионы,**
- **Спортның су төрләре өчен төзелгән сарай,**
- **Теннис академиясе,**
- **“Ак Барс” көрәш сарае,**
- **“Санкт-Петербург” волейбол үзәге,**
- **Бокс һәм өстәл теннисы үзәге,**
- **Урта Кабан күлендәге ишкәкләү каналы.**

Казанда узган Универсиада Бөтендөнья студентлар уеннары тарихында иң зурысы булды, уеннарда 160 илдән 7980 спортчы һәм 3798 рәсми затлар, шул исәптән Россия командасының 663 спортчысы катнашты.
Универсиаданың судьялык итү вазифасын 2158 судья башкарды, шуларның 766 сы халыкара квалификацияле.
Универсиаданың спорт программасында 27 спорт төре бар иде.
Медальләр рекордлы санда – 351 комплект уйнатылды.
Россия спортчылары Казандагы уеннарны ышанычлы рәвештә беренче гомуми команда урынын яулап, тантаналы төстә тәмамладылар. Алдагы Универсиадаларның барлык медальле рекордлары җиңелде. Россия җыелма командасы барлыгы 292 медаль яулады, шуларның 155е алтын, 75е көмеш, 62се бронза.
Россия җыелма командасы җиңүенә Татарстан студент-спортчылары зур өлеш кертте. Татарстан спортчылары тарафыннан 40 медаль яуланды, шуларның 20се алтын, 10сы көмеш, 10сы бронза, бу Россия Федерациясе

җыелма командасы алган медальләрнең гомуми санының 13,7% тәшкил итә...

Татарстанның спорт өлкәсендәге данын **«Ак Барс»**, **«Рубин»**, **«УНИКС»**, **«Зенит-Казань»**, **«Синтез»**, **«КАМАЗ-мастер»**, **«Динамо-Казань»** һәм башка командаларның җиңүләре тагы да арттыра.

**Казан. Спорт** https://www.kzn.ru/napravleniya-raboty/sport/?lang=ta

Казан берничә тапкыр эре спорт вакыйгаларының үзәгенә әверелде. 2013 елда Татарстан башкаласында XXVII Бөтендөнья җәйге студентлар уеннары үтте, 2015 елда Казанда Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты узды. Ике елдан соң, 2017 елда, шәһәр FIFA конфедерацияләр Кубогы матчларын, ә 2018 елда – Футбол буенча дөнья чемпионатын кабул итте. Алар барысы да халыкара экспертлар тарафыннан югары бәяләнде, ә бу вакыйгаларга старт биргән Универсиада шәһәрнең спорт инфраструктурасын үстерү, физкультура һәм спортны популярлаштыру өчен көчле этәргеч булды.

Бүген Казанда 2 меңнән артык спорт объекты – футбол кырлары, волейбол һәм теннис кортлары, йөзү бассейннары, спорт комплекслары исәпләнә. 2019 елның 1-нче гыйнварына Казанда 532 меңнән артык кеше, ягъни шәһәрлеләрнең гомуми саныннан 45%-ы даими рәвештә физкультура һәм спорт белән шөгыльләнә.

Ел саен шәһәрнең меңләгән халкы, һәвәскәрләр һәм профессионаллар спорт-массакүләм чараларында катнашалар, алар арасында «Россия чаңгы юллары» Бөтенроссия чаңгы ярышлары, «Милләтләр кроссы» бөтенроссия йөгерү көне, «Алтын алка» һәм «Күн туп» турнирлары, урам баскетболы буенча «Кызгылт сары туп» бөтенроссия ярышлары, Казан җиңел атлетика марафоны, Казан ярыммарафоны, традицион Беренче май җиңел атлетика эстафетасы, Казан чаңгы марафоны һәм башкалар...

**Казан. Спорт** https://www.kzn.ru/ https://www.kzn.ru/o-kazani/istoriya-kazani/?lang=ta

Меңьеллык тарихы булган шәһәр, студентлар һәм спорт үзәге буларак, яшь рухлы.




Аның мирасы 2015 елгы Су спорт төрләре буенча XVI FINA дөнья чемпионатын, 2017 елда FIFA Конфедерацияләр Кубогы матчларын, 2018 елда Футбол буенча дөнья чемпионаты матчларын уздырырга мөмкинлек бирде.

Шәһәрнең спорт инфраструктурасына 15 стадион, 12 ябык боз аренасы, 54 йөзү бассейны, 378 спорт залы һәм 942 спорт мәйданчыклары керә.

45 мең кеше сыйдырышлы "Казан Арена" (2019 елдан “Ак Барс Банк Арена” исемен йөртә) футбол стадионы –Россиядә 2018 елгы мундиаль уздыру өчен төзелгән беренче стадион шәһәрнең чын бизәге булып тора. 2013 елда “Казан Арена”да Бөтендөнья җәйге студентлар уеннарын ачу һәм ябу тантаналары узды. 2015 елда стадионда Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты кысаларында йөзү һәм синхрон йөзү буенча ярышлар узды. 2017 елда "Казан Арена" Конфедерацияләр кубогының 4 матчын, 2018 елда Футбол буенча FIFA дөнья чемпионатының алты матчын кабул итте. Стадионда үз өй матчларын Казанның "Рубин" футбол клубы үткәрә. Биредә шулай ук Россия җыелма командасы уеннары, Еврокубок матчлары узды.

Казанда мегавакыйгалар оештырудан тыш, спортның төбәк дәрәҗәсендә генә түгел, ә бөтенроссия дәрәҗәсендә дә үстерү тәэмин ителә, федераль спорт-тренировка үзәкләре (Ишкәкле спорт төрләре үзәге, Гимнастика үзәге, Теннис академиясе h.б.), махсус югары уку йортлары (Идел буе физик культура, спорт һәм туризм дәүләт академиясе һәм 2013 елгы Универсиада Авылы территориясендә яңа уку кампусы) ачыла, чемпион-клублар өчен шартлар тудырыла ("АК барс" хоккей клубы һәм "Рубин" футбол клубы).

Спорт объектлары саны һәм сыйфаты, аларның халыкара стандартларга туры килүе аркасында Татарстан башкаласы үз территориясендә эре спорт ярышлары оештырган өчен илнең һәм дөньяның башка эре шәһәрләре белән уңышлы көндәшлек итә ала.

**Татарстан Республикасы спорт министрлыгы**

http://minsport.tatarstan.ru/tat/index.htm/news/

Миссия

Максатлары һәм бурычлары

Җитәкчелеге

Структурасы

Ведомство карамагындагы оешмалар

Тарих

Физкультура-спорт җәмгыятьләре

**Татар-информ** https://tatar-inform.tatar/

Көн үзәге

Интертат

Фото

Видео

**Казан Россиянең спорт башкаласы исеменә лаек дип табылды**

https://tatar-inform.tatar/news/sport/14-12-2009/kazan-rossiyane-sport-bashkalasy-isemen-laek-dip-tabyldy-4821501

«Советский спорт» федераль басмасы сайтында үткәрелгән он-лайн тавыш бирү нәтиҗәләре шуны күрсәтә

(Казан, 14 декабрь, «Татар-информ»). «Советский спорт» федераль басмысы сайтында он-лайн режимында үткәрелгән тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, Казан Россиянең спорт башкаласы исеменә лаек дип танылган.

Бүген Мәскәүдә номинацияләр буенча җиңүчеләрне игълан итү тантанасы була, алар исә «Россиянең Алтын командасы»н тәшкил итә һәм тантанага

Казан мэры Илсур Метшин да чакырулы, дип хәбәр сала Казан шәһәре Думасы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм матбугат чаралары белән элемтәләр бүлеге.
РФ Спорт, туризм һәм яшьләр сәясәте министрлыгы, «Советский спорт» һәм «Комсомольская правда» федераль газеталары оештырган әлеге акциядә Казан, шактый алга китеп, беренче булган, икенче урында – Мәскәү, өченче урында – Санкт-Петербург, ә акциядә Сочи, Пенза, Ханты-Мансийск һ.б. шәһәрләр катнашкан.
Тавыш бирү «Елның спорт корылмасы», «Ел җиңүе», «Ел спортчысы», «Елның спорт проекты» һ.б. - барлыгы 7 номинациядә булып, ул «Россиянең Алтын командасы» илкүләм премиясен бирү кысаларында уздырылган.

**FINA World Championships KAZAN Russia 2015**

**Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты**

http://ru.kazan2015.com/tat/about_kazan

**Шәһәрдә спорт**

Казан Россия спорты үсеше локомотивы һәм спортның төрле төрләре буенча Россия һәм Европа дәрәҗәсендәге чемпионатларда, шулай ук Олимпия уеннарында да ышанычлы чыгышлар ясаучы титуллы спортчылар һәм спорт клублары йорты. Соңгы елларда шәһәрнең спорт корылмаларында спортның төрле төрләре буенча халыкара ярышлар уздырыла.
Казанда 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиаданы уздыру Казанда гына түгел, Россиядә дә балалар, яшьләр һәм студентлар спортын үстерүгә этәргеч бирде. Халыкара спорт аренасында Казан бик яхшы танылган шәһәргә әверелде. Казанның кунакчыллык күрсәтү мөмкинчелекләре, ягъни реконструкцияләнгән аэропорты, үсеш алган кунакханә инфраструктурасы, заманча шәһәр юллары системасы һәм спортка кагылышлы төрле корылмалары булуы эре халыкара ярышларны югары дәрәҗәдә үткәрергә булыша.

2014 елны Казан халыкара спорт ярышларын кабул итте. Болар – бадминтон буенча Европа чемпионаты, яшүсмерләр арасында авыр атлетика буенча дөнья беренчелеге, фехтование буенча дөнья чемпионаты, хай-дайвинг буенча I ФИНА Дөнья Кубогы һәм Россия тарихында беренче тапкыр уздырылган "Фэйр плей" ("Гадел уен") халыкара премиясен тапшыру тантанасы.

2015 елда Казанда Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты һәм Су спорт төрләре буенча спорт ветераннары һәм үзешчән спортчылар арасында "Мастерс" категориясендәге дөнья чемпионаты узды. 2018 елда Казан, Россиянең башка шәһәрләре рәтендә, Футбол буенча дөнья чемпионаты матчларын кабул итәчәк.

**Бөтендөнья татар конгрессы** http://tatar-congress.org/yanalyklar/kazanda-sportnyn-su-torlere-buencha-xvi-donya-chempionaty-achyla/

**Казанда спортның су төрләре буенча XVI дөнья чемпионаты ачыла**

Кадерле татарстанлылар!

2015 елның 24 июлендә Казанда спортның су төрләре буенча XVI дөнья чемпионаты ачыла. Анда 190 илдән 5400дән артык спортчы, шул исәптән 1161 Россия Федерациясе спортчысы көч сынашачак. Төп чемпионатта су спортының – алты, ә «Мастерс» турнирында – биш төрендә ярышлар булачак.

Спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты тамашачыларда кызыксыну, игътибар җәлеп итү дәрәҗәсе ягыннан дөньяның футбол мундиаленнән кала икенче урында тора, ә Казандагы ярышлар аларда катнашучы спортчылар һәм илләр саны буенча рекорд куячак. Татарстан башкаласындагы су бәйрәмен бөтен Җир шарында 4,5 миллиардтан артык кешегә телевизор экраннарыннан карау мөмкинлеге бирелә.

Спортчылар 75 комплект медаль өчен ярыша.

Бу көннәрдә без Россия спортчыларыннан һәм Россия җыелма командасы составындагы якташларыбыздан зур җиңүләр, ә анда катнашкан һәркемнән көрәш дәрте һәм спортта югары күрсәткечләргә ирешүләрен көтәбез.
Әлеге чемпионат – спорт өлкәсендә 2015 елда иң әһәмиятле дөньякүләм чараларның берсе, ә Татарстан һәм Россия тарихында – гаять күренекле вакыйга. Бу абруйлы халыкара чараны уздыру Россия Федерациясе Президенты Владимир Владимирович Путин һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте, Халыкара ФИНА йөзү федерациясе ярдәме нәтиҗәсендә мөмкин булды. Ул – спорт объектларын әзерләүдә һәм ярышларны үткәрүдә катнашкан татарстанлыларның уртак тырышлык нәтиҗәсе.
Шунысын әйтергә кирәк: 2013 елда Казандагы XXVII Бөтендөнья студентлар уеннары шәһәребез спорт һәм транспорт инфраструктурасының нык үсүенә, халыкара дәрәҗәдәге корылмалар һәм объектлар төзелүенә китерде. Универсиада калдырган мондый мирас татарстанлыларның мәнфәгатьләренә, күмәк спорт һәм физкультура белән шөгыльләнүчеләр санын арттыруга хезмәт итә. Гамәлдәге спорт базасы талантлы спортчылар әзерләү мәйданчыгы булып тора, ә бу чемпионат һәм якындагы елларда уздыру планлаштырылган бик күп спорт төрләре буенча дөньякүләм башка ярышлар Казанның илебез спорт башкаласы дигән статусын ныгыта.
Универсиаданы уздыру барышында тупланган оештыру тәҗрибәсе һәм барлык дәрәҗәләрдә булдырылган контактларның әлеге чемпионатта да бик кирәкле булуын әйтеп китәр идем.
Бу елларда республикабыз, аның мәркәзе Казан шактый үзгәрде, матурланды. Кризис күренешләренә һәм Көнбатыш санкцияләренә карамастан, Татарстан икътисады тотрыклы үсештә. Кама индустриаль кластеры предприятиеләре, «Алабуга» махсус икътисадый зонасы, Иннополис үсешебезгә этәргеч бирә торган яңа таяныч нокталары булды. Милләтара һәм динара татулыкны һәм тынычлыкны саклап калу, килешенгән, кешеләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлтелгән социаль сәясәт, мәгариф һәм фән өлкәсен үстерү, талант ияләренә төрле яклап булышлык күрсәтү республиканың

социаль-икътисадый алгарышында өстенлекле юнәлешләр булып кала...

**Азатлык радиосы** https://www.azatliq.org/a/25161103.html

**Казан дөньякүләм спорт башкаласы исемен йөртергә мөмкин шәһәрләр исемлегенә кергән**

Лондонда кичә төнлә ISEM - спорт чараларын иң яхшы оештыручы дип саналган шәһәрләргә халыкара бүләк тапшыру тантанасы узды. Дубай, Лондон һәм Окленд белән бергә дөньякүләм белгечләр Казанны дә халыкара спорт чараларын оештыру өчен иң уңышлы шәһәр дип билгеләгән. Татарстан башкаласы "Highly recommended sport city" номинациясендә бүләк тапшырылган.

Шулай итеп дөньякүләм спорт башкаласы исемен йөртергә мөмкин дүрт шәһәр исеменә Казан да эләккән.

**Идел** http://idel-tat.ru/news/novosti-tt/kazan-2025-elda-su-sport-trlre-b

**Казан 2025 елда Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионатын кабул итәчәк**

Казан тарихта икенче тапкыр Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионатын кабул итәчәк. Татарстан башкаласы әлеге ярышларны беренче тапкыр 2015 елда кабул иткән иде.  Ярышлар Татарстан башкаласында 2025 елда узачак. Әлеге карар Халыкара йөзү федерациясе бюросы утырышында кабул ителде. «Ун елдан соң – тарих кабатлануы матур вакыйга булыр иде», — диде Татарстан спорт министрлыгы башлыгы Владимир Леонов журналистларга. Моннан тыш, Казан 2023 елда Катар урынына дөнья чемпионатын кабул итәргә әзер. "Катарның футбол буенча дөнья чемпионаты уңаеннан җитди йөкләнеш бар, без моны күрәбез. 2023 елда дзюдо буенча дөнья чемпионаты һәм 2023 елда Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионатын уздыру-бу инде артык булыр иде. Бездә барлык инфраструктура әзер һәм без дөнья чемпионатын иртәгә дә уздырырга әзер», — дип билгеләп үтте Леонов. Татарстан башкаласы шулай ук 2022 елда Кыска суда йөзү буенча дөнья

чемпионатын кабул итәчәк, 2021 елда шул ук төр буенча Европа чемпионатын, 2022 елда исә Европа комплексы чемпионаты кысаларында йөзү һәм ишү буенча ярышлар уздырырга вәгъдә итә.

**Матбугат ру** https://matbugat.ru/news/?id=1774

**«Безнең спорт» − спорт турында беренче татар гәзите**

**Татарстан**

http://protatarstan.ru/%D1%80%D3%A9%D1%81%D1%82%D3%99%D0%BC-%D0%BC%D0%B8%D2%A3%D0%BD%D0%B5%D1%85%D0%B0%D0%BD%D0%BE%D0%B2-%D0%BA%D0%B0%D0%B7%D0%B0%D0%BD-%D0%BA%D0%BE%D0%BC%D0%B0%D0%BD%D0%B4%D0%B0%D0%BB%D0%B0%D1%80%D1%8B/

**Рөстәм Миңнеханов: Казан командалары бүген – Россиянең танылган спорт брендлары**

Татарстан Президенты сүзләренчә, Казанның «Рубин», «Ак Барс», «Зенит» һәм УНИКС командаларын илдә һәм аннан читтә дә таныйлар.

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов «Совет спорты»на биргән интервьюсында Казанның спорт командалары “илдә иң якты спорт брендларының берсе” булып тора, дип атаган. Искәртеп үтик, Татарстан «Совет спорты» эксперт советы төзегән төбәкләрнең спорт рейтингында лидер булды.

«Хәзерге вакытта республикада яшәүчеләр өчен 10,5 мең спорт корылмасы, шул исәптән 44 стадион, 2000 ләп спорт залы, 187 бассейн, 40 ябык боз шугалагы хезмәт күрсәтә. Билгеле, без алга таба да спорт инфраструктурасын үстерергә ниятлибез. Безнең яңа федераль программа кысаларында, 2020 елга чираттагы өстенлекле проект булып, 100 миллион сумга кадәрге аз бюджетлы спорт корылмалары булдыру тора. Татарстанлылар өчен яшәү урыннарында төзелгән универсаль спорт мәйданнары зур ярдәм булды. Быел 419 миллион сумлык 188 спорт мәйданчыгы сафка бастырылды, ә 4 ел эчендә

эшләп килгән республика программасы буенча яшәү һәм уку урыннарында 671 спорт мәйданы төзелде», – дип җиткерде интервьюда Президент.
Рөстәм Миңнеханов Россия командаларының Россия һәм Европа ареналарындагы җиңүләрен игътибарсыз калдыра алмады. «Бүген Татарстан Республикасы профессиональ командалары – Россиянең танылган спорт брендларыннан, алар безнең визит карточкасы һәм горурлыгыбыз. Көчле спорт командалары төбәкнең билгеле бер йөзен булдыруда мөһим роль уйный. Бүген «Рубин», «Ак Барс», «Зенит», УНИКС, «Динамо-Казан» һәм башка клубларны Татарстанда һәм Россиядә генә түгел, ә Европада да беләләр», – дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов.
Чыганак: «Татар-информ»